ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 5 Димтамак ав. 28 гыйнвар 2022 ел

Татарстан республикасы Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге Советының 2021 елның
5 июлендәге «Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» гы
8 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамакавыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советының 2021 елның 5 июлендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы 8 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

1.1. 6.1 пунктта. түбәндәге эчтәлекле «К» пунктчасы өстәргә:
к) йорт территориясендә үсеп килүче яшел үсентеләрне тиешле хәлдә тоту, авария-куркыныч тудыручы һәм коры-сары ботакларны кисәргә, авария-куркынычтудыручы һәм коры-сары агачларны бетерергә.
1.2. 6.2 пунктта. "П» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
п) йорт янындагы территориядә клумбалар, чәчәк түтәлләре, декоратив коймалар һәм кече архитектура формалары буларак автомобиль покрышкалары куллану.

2. Әлеге карар махсус мәгълүмат стендларында рәсми халыкка игълан ителгән көннән, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырылган көннән һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча кабул ителгән көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Димтамак авыл җирлеге башлыгына йөкләнә.

Димтамакавыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов